ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 28.10.2020 г. Казань № 124-17/кс-2020

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен ташландык суларны агызуга 2018 елның 28 ноябрендәге 10-84/кс номерлы карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2021 елга төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, ташландык суларны агызуга 2021-2023 елларга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай кеременә төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019-2023 елларга ташландык суларны агызуга тарифлар билгеләү турында» 2018 елның 28 ноябрендәге 10-84/кс номерлы карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 20 ноябрендәге 10-78/кс номерлы карары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 28.11.2018 № 10-84/кс карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 28.10.2020 № 124-17/кс-2020 карары редакциясендә)

## Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019-2023 елларга ташландык суларны агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә

| № т/с | Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу белән шөгыльләнүче оешма, муниципаль берәмлек исеме | Ел | Ташландык су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Питрәч муниципаль районы | | |
| 1 | «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 15,53 |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 15,91 |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 15,91 |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 16,19 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 16,19 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 16,72 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 16,72 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 17,09 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2023 башлап<br>30.06.2023 кадәр | 17,09 |
| | | 01.07.2023 башлап<br>31.12.2023 кадәр | 17,65 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
28.11.2018 № 10-84/кс
карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
28.10.2020 № 124-17/кс-2020 карары редакциясендә)

Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019-2023 елларга ташландык суларны агызуга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары

| № т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суларны агызуны хәл итүче оешма исеме, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Норматив табыш дәрәҗәсе | Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма чыгымы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·сәг/куб.м |
| 1 | «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Ташландык суларны агызу | 2019 | 1436,20 | X | - | - | 0,937 |
| | | 2020 | X | 1 | - | - | 0,937 |
| | | 2021 | X | 1 | - | - | 0,937 |
| | | 2022 | X | 1 | - | - | 0,937 |
| | | 2023 | X | 1 | - | - | 0,937 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге